**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы**

Актүбә ш.т.б. № 19 «24» апрель 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 13 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай мунициипаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мунициипаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (11.11.2016 № 18, 25.09.2017 № 21, 15.02.2018 № 4, 16.12.2019 № 51, 30.01.2020 № 3 карарлар редакциясендә)

2019 елның 2 августындагы 301-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенец аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 13 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә (11.11.2016 № 18, 25.09.2017 № 21, 15.02.2018 № 4, 16.12.2019 № 51, 30.01.2020 № 3 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 бүлекнең 3 пунктында "федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән илле мең тапкыр артып китә" сүзләрен "федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән 10 тапкыр артып китә" сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 11 бүлекнең 3 абзацында "федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләме илле мең тапкырдан артып китә" сүзләрен "Ачык җәмгыять устав капиталының федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 50 тапкырдан артык"сүзләренә алмаштырырга..

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми

сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галеева